ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасында физик затлар мөлкәтенә 2016 елгы салым чорында түләнергә тиешле салым буенча недоимка суммасына пеня исәпләнә башлау датасын билгеләү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 21 декабрендә
кабул ителде

## 1 статья

Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 75 статьясының $4^1$ пункты нигезендә Татарстан Республикасында физик затлар мөлкәтенә 2016 елгы салым чорында түләнергә тиешле салым буенча недоимка суммасына пеня 2018 елның 1 июленнән башлап исәпләнә дип билгеләргә.

## 2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2017 елның 1 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2017 ел, 22 декабрь
№ 96-ТРЗ